**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Шубан авыл җирлегенең Гондыр авылында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2022 елның 2 ноябре. №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Шубан авыл җирлегенең Гондыр авылында **халык җыены карар бирә**:

1. . Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына узарасалымның 90% һәм 50% күләмендә ташлама билгеләнгән 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, 90 яшьтән өлкәнрәкләрдән, авырып ялгыз яшәгән өлкән пенсионерлардан һәм тыл хезмәтчәннәреннән кала, Шубан авыл җирлегенен Гондыр авылында теркәлгән,балигъ булган һәр гражданга 2023 елда узарасалымны 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Гондырево авылы чишмәсен төзекләндерү;
- Чишмәгә бара торган кечкенә күперне ремонтлау.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга , http:// pravo.tatarstan.ru. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе: С.З.Васильева